| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕШИРДАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Г.Тукая, 10, с.Большие Ширданы, 422500 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕНЕҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>Г.Тукай ур., 10, Олы Шырдан., 422500 |
|---|---|---|
| Тел./факс: (84371) 2-30-12. E-mail: Bsrd.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan.ru | | |


**КАРАР**

**Олы Шырдан авылы**

**12.09.2022 ел** **№ 14**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Шырдан авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 18 ноябрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм Олы Шырдан авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. ТР Зеленодольск муниципаль районының Олы Шырдан авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашуының формалары булып торуын билгеләргә:

- эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;
- үз милкендәге биналарда һәм корылмаларда янгыннарны сүндерүнең беренчел чараларының булуы;
- янгын ачыклангандa, алар турында шунда ук янгын сагына хәбәр итәргә;
- янгын сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне һәм янгынны сүндерү буенча көчдән килгәнчә чаралар күрү;
- янгынны сүндергәндә янгын сагына ярдәм күрсәтү;
- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелегенең вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне контрольдә тоту һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында үзләренә караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны тикшерү һәм тикшерүләр үткәрү мөмкинлеген бирү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-

телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмати стендларда: Олы Шырдан авылы, Г.Тукай урамы, 10 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Шырдан авылы, Киров урамы, 6 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Олы Шырдан Башлыгы** **Кәримов Р. Р.**